


### Март ае бәйгеләре

**/Безнең уңышлар/**

16 нчы март көнне район үзәгендә **“Живая классика”** конкурсы уздырылды. Бу бәйгедә укучылар рус классик язучыларының проза әсәрләреннән өзекләр сөйләргә тиешләр Конкурсның муниципаль турында безнең укучыларыбыз да актив катнашты. **Гафиятуллин Фаил** (V сыйныф) – призер, **Нургалиева Ләйлә** (VI сыйныф) белән **Хәйруллин Айназ** (VII сыйныф) лауреат исеменә лаек булдылар. Конкурсны бәяләүче район комиссиясе әгъзалары билгеләргәнчә, безнең мәктәп укучылары башка авыллардан килгән катнашучылар белән чагыштырганда акцентсыз сөйли алулары белән аерылып торалар. Укучыларга киләчәктә дә зур уңышларга ирешүләрен теләп, аларны әзерләгән укытучылары **Нәҗметдинова Раушания апага** рәхмәт белдерәбез.

Шулай ук узган айда **Л.Н.Толстой исемендәге** XX нче республикакүләм фәнни-практик конференциясенең муниципаль турында X сыйныф укучысы **Нукина Виктория** (Җитәкчесе **Кадырова Гөлнур апа**) җиңүче булды. Викторияне бу җиңүе белән котлап, тагын да зуррак уңышлар телибез.

Һәр елдагыча безнең укучылар **Туфан укуларында** актив катнашып килә. Быелгы конкурста безнең укучыларыбыз **Насыйрова Кәүсәр** (IV сыйныф) һәм **Нукина Виктория** (X сыйныф) II урыннарны яуладылар.

***Илдар Сафиуллин, уку-укыту эшләре буенча директор урынбасары***

### Өяз шәһәре музеенда

**/Безнең сәяхәтләр/**



Күптән түгел, 16 март көнне, директорыбыз Рафик абый безне Чистайдагы “Өяз шәһәре музее”на алып барды. Бу музейга 1921 елда натуралист һәм археолог Александр Константинович Булич нигез сала. Экспозицияләрнең зур өлеше 19 гасыр – 20 нче гасыр башы Чистай тарихына багышланган. Ул чорда Чистай Казан губернасының эре сәүдә үзәге саналган.

Музейның уникаль экспонатлары булып, 20 гасыр башында, Чистайда яшәүче Н.И.Мельников тарафыннан ясалган агач велосипедлар тора. Бу музейда безгә иң ошаган урын – безнең якта яшәгән кош-кортлар һәм хайваннарның манекеннары һәм йомыркалар коллекциясе. Бу экспонатлар чын хайваннардан һәм кошлардан ясалуы белән үзенчәлекле. Шунлыктан алар чыннан да исән кебек күренәләр. Шулай ук экспозицияләр арасында борынгы Җүкәтау шәһәрчегеннән табылган көмеш тәңкәләр һәм зәркән бизәнү әйберләре, хезмәт һәм сугыш кораллары, көнкүреш җиһазлары зур кызыксындыру уята. Музейда тагын безнең якта яшәгән төрле халыкларның милли киемнәре, элеккеге Чистай кешеләренең өй һәм кибет күренешләре бик кызыклы.

Чистай шәһәре бездән ерак түгел, һәм анда барыбызның да булганы бардыр. Мәктәптәге барлык укучыларга, әти-әниләргә, һәм гомумән, авылның барча кешеләренә Чистайдагы музейларны барып карарга киңәш итәбез.

***Зөлфирә Сафиуллина, X сыйныф укучысы***

### Чистай музей-күргәзмә комплексында

Чистайга сәяхәтебез барышында без бу шәһәрнең элеккеге бай сәүдәгәре Чукашев өендә урнашкан музей-күргәзмә комплексын карап чыктык. Биредә барлыгы 10 экспозиция залы бар.

Күргәзмәләр белән танышуыбыз Чистай сәгать заводы күргәзмәсеннән башланды. Биредә заводның эшләү дәверенә чыгарылган продукция үрнәкләре, тарихи документлар һәм завод макеты урнаштырылган. Заводның тарихы Бөек Ватан сугышы елларында Мәскәү шәһәрендәге 2 нче сәгать заводын Чистайга эвакуацияләүдән башланып китә. 1942 елның 1 июле Чистай сәгать заводының туган көне дип санала. 1943 нче елның җәендә завод беренче продукциясе – К-43 маркалы яки халык арасында “Кировский” дип исемләнгән кул сәгатьләре чыгарыла башлый. 1946 нчы елдан башлап танылган “Победа” кул сәгатьләре, механик йөрешле секундомерлар, диңгез һәм автомобиль сәгатьләре, сәгать җитештерүе өчен станоклар чыгару җайга салына.

Чираттагы күргәзмә Бөек Ватан сугышы темасына багышланган иде. Биредә Сталинград янында табылган кораллар, бомба кисәкләре, солдатларның көнкүреш әйберләре куелган. Аннан соң СССРда иң популяр булган транспорт төре – мотоцикллар экспозициясе белән таныштык. Музей хезмәткәре әйтүенчә, бирелдәге техника барысы да төзек һәм хәзер дә файдаланырлык. Минем өчен аеруча Совет чоры көнкүрешенә багышланган күргәзмә истә калырлык булды. Биредә безнең әти-әниләр һәм әби-бабайлар яшәгән 1960-1980 нче еллардагы киемнәр, мебель, йорт кирәк-яраклары, китаплар, пластинкалар урын алган. Ул бүлмәгә керүгә үзеңне шул заманга кайткан кебек хис итәсең.

Безнең өчен бу экскурсия бик кызыклы булды. Башкаларга да Чистай музейларын күреп кайтырга киңәш итәбез.

***Әминә Туктамышева, X сыйныф укучысы***


Газетаны гамәлгә куючы – Түбән Майна урта мәктәбе
Мөхәррир – Фәнүзә Гафиятуллина
Редколлегия әгъзалары:
Әминә Туктамышева, Виктория Нукина, Зөлфирә Сафиуллина, Сара Насыйрова, Рузилә Мөхәммәтова



# Мәктәп хәбәрчесе

**№3 (№34) март 2022 ел**

**Түбән Майна урта мәктәбе газете**

**Тел. 8 (84344) 4-38-46** **sch1644maina@mail.ru**


**/ Мөгаллим минбәре /**

### Математик белемлелек турында

Бүгенге көндә гомуми белем бирү системасында **функциональ белемлелекне** (грамоталылыкны) формалаштыру өстенлекле максатларның берсе булып тора. Шуны күздә тотып, үзебезнең газит битләрендә әлеге мөһим теманы яктырткан мәкаләләр урнаштыра башладык. Бу санда математик белемлелеккә тукталып үтәргә булдык.

**PISA (Programme for International Student Assessment)** халыкара тикшеренүләре буенча “функциональ математик грамоталык” төшенчәсе “укучының мәктәптә уку дәверендә алган математик белемнәрен төрле предметара һәм гамәли юнәлешле мәсьәләләрне чишүдә, җәмгыятьтә социаль мөнәсәбәтләрдә уңышлы куллана белү” дип аңлатыла.

Математик белемлелек укучылардан түбәндәге күнекмәләргә ия булуны таләп итә:

- дөньяда барлыкка килә торган проблемалар арасыннан математик белемнәргә таянып чишеп була торганнарын аера белү;
- аларны математик белемнәр һәм алымнар кулланып чишү;
- чишелешне математик фикерләүләргә нигезләү;
- кулланылган чишү алымнарын анализлау;
- табылган нәтиҗәләрне куелган максат мәсьәләләрне куеп-чагыштыру.

### 8 март – Халыкара хатын-кызлар көне белән!




Бүгенгесе көндә балага әзер белем генә бирү җитми, ә аны укырга һәм фикерләргә өйрәтү зарур, һәм инде иң мөһиме – алган белемнәрне тормышта куллана белергә өйрәтү. Үземнең тәҗрибәмнән чыгып әйтә алам, соңгы елларда математика буенча тикшерү эшләрендә реаль тормыштан алынган биремнәр кертелә башлады. Шулай ук 9 нчы сыйныфларның ТДИ (ОГЭ) эшләрендә 1-5 биремнәр гамәли юнәлештәге биремнәрдән тора. Алар арасында теплица, автомобиль шинасы, төзү эшләрендә проектлаштыру, финанс ягыннан отышлы вариантларны исәпләү, элемтә һәм интернет белән бәйле булган һ.б. шундыйрак биремнәр бар. Моның өчен укыту процессын баланың үзендә укырга теләк һәм омтылыш уянырлык итеп оештырырга, чынлап та белемнәрнең олы тормышта кирәклегенә төшендерергә кирәк. Мисал өчен, мәктәп математика курсында өйрәнелә торган, берничә генә теманың тормышта әһәмиятле булуын күрсәтүгә тукталам.

«Унарлы вакланмалар белән гамәлләр» темасы 5 нче сыйныфта өйрәнелә. Әлеге теманың кирәклеген гаиләнең кулланылган ут һәм газ энергияләре өчен түләүне исәпләү мисалы өстендә аңлатырга мөмкин. Мондый бирем башкарганда укучылар квитанция белән дә таныша, счетчик күрсәткечләрен дә белергә өйрәнә. Мондый биремнәр ТДИ һәм БДИ эшләрендә дә бар, кулга квитанцияне кулга тотып эшләгәч, ул аларның исендә нык саклана дип уйлыйм.

Геометрия курсында “Мәйданнар” темасын өйрәнгәндә, тормышта төрле һөнәр ияләренә әлеге теманың ничек кирәклеген, я булмаса өйдә стенага обой ябыштыру, идәнгә линолеум җәю кебек эшләрне башкарганда, яисә бәрәңге бакчалары күпме урын алып торганлыгын исәпләүдә – конкрет мисалларда-мәсьәләләрдә аңлатырга тырышам.

Яки процентлар темасын алыйк. Хәзерге заман баласына дәрестә процентның нәрсә икәнен аңлату гына җитми, аларга шул процентны дөрес кулланырга да өйрәтергә кирәк. Тирә-юньдә процент белән эш итә белмичә “бурычлар чокырына “ чумучы кешеләр бик күп. Мәктәп парталары арасында укучыларга дөрес юнәлеш бирү - безнең бурыч.

Математика – иң авыр фәннәрнең берсе. Укучылар арасында сораштырулар уздырганда, математиканың балалар өчен иң кыен да, шул ук вакытта иң кирәкле дә фән икәне ачыклана. Мәктәптә эшләү дәверемдә төрле үзгәрешләр чорын үтәргә туры килде. Дөнья үзгәрә, балалар да үзгәрә. Теләсәк тә, теләмәсәк тә яңа чор укучылары белән бергә атларга, чыгарылыш укучыларының җитди максатларына ирешергә мөмкинлек бирердәй, аларның юлларында килеп чыккан тормыш каршылыкларын һәм четерекле очракларны уңышлы үтеп чыгардай белемнәр белән тәэмин итеп, аларга тормышта үз юлларын табарга булышырга тиешбез.

***Фәнил Зарипов, математика укытучысы***.

## /Рәсми хәбәрләр/

26 нчы март көнне 2021/2022 нче уку елының III нче чиреге төгәлләнде. Чирек нәтиҗәләре күрсәткәнчә, мәктәп буенча белем сыйфаты 58,3% тәшкил итте. Чирекне гел “бишле” билгеләренә IV сыйныфтан **Закирова Ләйсән**, IV сыйныфтан **Гафиятуллин Фаил** тәмамлады. Язгы каникуллар 28 марттан 6 нчы апрельгәчә дәвам итәчәк. Каникул көннәрендә чыгарылыш сыйныфларның әзерлек дәрәҗәсен тикшерү максатыннан 28 нче марттан 31 нче март аралыгында математика, рус теле, рус әдәбияты һәм җәмгыять белеменнән XI сыйныфлар, IX сыйныф математика, биологиядән район үзәгендә сынау имтиханнары уздырылачак. Калган сыйныфларда быел яз уздырылырга тиешле Бөтенроссия тикшерү эшләре (ВПР) агымдагы елның көз айларына күчерелә.

***Илдар Сафиуллин, укыту эшләре буенча директор урынбасары***

## /Мәктәп тормышы/



### Матур язу сәнгате

**Каллиграфия** – сынлы сәнгатьнең бер тармагы булып тора. Әле аны еш кына “Матур хат” сәнгате дип тә атыйлар. Бармак эзе яки тавыш уникаль булган кебек, ул һәр кеше өчен үзенчәлекле. Матур, төгәл һәм ачык язу – культураның аерылгысыз билгесе. Гадәти әңгәмә вакытында да без һәрвакыт зәвыклы булмаса да, аңлаешлы матур сүзләр кулланып сөйләшергә тырышабыз. Матур сөйләмне үстерү өстендә эшлибез. Язу да шулай ук аңлаешлы һәм матур булырга тиеш. Бу турыда Британия калиграфы һәм язучысы Альфреда Фербанк менә нәрсә ди: “Кешеләр ачык кына түгел, зәвыклы һәм грация белән дә сөйләшергә телиләр. Шулай ук язарга да кирәк: язу матур булырга тиеш. Башкача әйткәндә, язуга сәнгатькә караган кебек карарга кирәк".

Язуның әһәмиятен искә төшерү йөзеннән мәктәбебездә башлангыч сыйныфлар арасында 14 нче февральдән алып 14 нче мартка кадәр **“Мин матур язам”** дип аталган конкурс үткәрелде. Бәйге барышында укучыларга атнасына икешәр эш биреп барылды. Хәрефләрне дөрес язу, дөрес тоташтыру элементларын куллану, язуның тигезлеге – боларны барысын да кабатлап узды укучыларыбыз. Ахырдан контроль күчереп язу булды.

Башлангыч сыйныф укытучыларыннан торган жюри составы соңыннан җиңүчеләрне билгеләде. Һәр катнашучы үз тырышлыгына карап бүләкләнде. 1 нче урынга –Закиров Инсаф, Камалов Илнур һәм Закирова Ләйсән лаек булды, 2 нче урынны – Насыйрова Кәүсәр яулады, 3 нче урынны – Донсков Артур белән Нурматова Асия бүлештеләр.

Укучыларыбыздан алдагы көннәрдә дә матур язуга игътибарны югатмауларын, язу өстендә күбрәк эшләүләрен сорап каласыбыз килә. ***Гөлшат Закирова, башлангыч сыйныф укытучысы***

### Юл йөрү кагыйдәләрен кабатладык



1 нче мартта укучыларга юл йөрү кагыйдәләре буенча ЮИД җитәкчесе Гафиятуллина Руфия апа ачык дәрес уздырды. Балалар катнашында юл фаҗигаләре гел кабатланып тора. Шундый авыр хәлләрне булдырмый калу максатыннан мондый дәресләр еш үткәрелә. Руфия апа алып барган бу юнәлеш район җитәкчеләре тарафыннан да югары бәяләнеп килә. Төрлечә уздырылган ярышларда да нәтиҗәле урыннар алып киләбез. Аның дәресләре безгә юлда игътибарлы булырга өйрәтә.

***Сара Насыйрова, XI сыйныф укучысы.***



### Цифрлаштыру дәресе

Белгәнебезчә, 2022 нче ел ил күләмендә **цифрлаштыру елы** буларак игълан ителде. Шул уңайдан Закирова Гөлшат апа безгә компьютерны куллана белү, аның файдалы һәм зыянлы ягы турында дәрес үткәрде. Укучыларга **кибербойлинг** турында төшенчәләр китерде. Укучылар интернет челтәренә фотолар урнаштырганнан соң күп кенә комментарийлар куела һәм, әлбәттә, алар арасында тискәре эчтәлеклеләре күп. Ә бу исә үз чиратында бала психологиясенә тискәре йогынты ясый. Интернет челтәренең куркынычы тагын шунда: балаларга парольләрне каядыр язу һәм таныш булмаган сайтларга керү куркыныч. Чит кешеләр белән язышу да төрле начар нәтиҗәләргә китерүе мөмкин. Болар барысы да берәмтекләп аңлатылды. Укучылар өчен бик файдалы мондый дәресләр тагын кабатланачак.

Цифрлаштыру дәресе ахырында “Мин интернетка каршы – мин китап укыйм” конкурсы игълан ителде. Бу бәйге нәтиҗәләре май аенда билгеле булачак. ***Виктория Нукина, Х сыйыф укучысы***

## /Безнең бәйрәмнәр/



### Кызлар ярышы

8 нче март – Халыкара хатын-кызлар көне. Шушы бәйрәм уңаеннан, мәктәптә кызлар арасында “Ягез әле кызлар” кичәсе уздырылды. Кызлар, “Умырзая” һәм “Киек казлар” командаларына бүленеп, үзләренең зирәклекләре, җитезлекләре, уңганлыклары буенча ярыштылар. Иң баштан таныштыру булды. Исем, девиз, җыр, эмблемаларын тәкъдим иттеләр. Аннан соң алдан әзерләп куйган шигырьләрен һәм нәсерләрен укып үттеләр. Шуннан тапкырлыкка бәйге узды. Анда алар мәкальләрне һәм табышмакларны дәвам итәргә тиеш иде. Иң уңган хуҗабикәләр кайсы командада икәнен билгеләү өчен сәдәф тагу, сыер саву, бәрәңге әрчү, йомыркадан ромашка ясау, өстәлне салфетка белән бизәү кебек ярышлар булды. Хатын-кыз гүзәллеген тагын да арттыру аксесуары – яулык бәйләү буенча бәйгеләр үтте. Ахырдан 8 төрле бию конкурсы булды.

Ярыш барышында “Умырзая” командасы алдан барса да, ахырдан “Киек казлар” алга чыкты һәм җиңү яулады. Бәйрәм кызлар өчен дә, калган укучылар өчен дә бик күңелле үтте.

***Виктория Нукина, Х сыйныф укучысы***

### Нәүрүз килә, Нәүрүз...



Март аеның иң күркәм, көтеп алынган чараларыннан берсе – Нәүрүз бәйрәмедер, мөгаен. Мәктәп укучылары гына түгел, авыл халкы да бу тамашаны, бигрәк тә, ярминкәсен үз итә. Ул көнне мәктәп тирәсе шау-гөр килә, һәркем сату өчен үзенә урын барлый. Кемдер мәктәп ишегалды “түрен” сәхнә итеп бизи. Иртән үк халык көйләре агымына кушылып самовардан төтен чыга. Ашханәдә пешекчеләр борынны кытыклап, әллә кайдан чакырып китерә торган тәмле исле коймагын чыжлата.

Менә чарага әзерләнеп беттеләр дә, концерт номерлары белән бәйрәм тамашасы үрелеп барды. Кызлар да, малайлар да төрле сынау уеннарында катнаштылар. Кем такта кисте, кем арбаларга иптәшен утыртып узышты, кайсыдыр себерке белән футбол уйнады. Уеннар һәр бала күңеленә хуш килде, ә иң мавыктыргычы – җәядән ату булды. Иң озак барган уен да шул иде. Хәйруллин **Данил** кебек оста атучы кеше булмагандыр.

Күптәннән килгән гадәт буенча, Нәүрүз бәйрәмендә без яз кунаклары – сыерчыкларны зурлап каршы алабыз. Бәйрәм барышында һәр елны сыерчык оялары ясаучылар билгеләп үтелә. Быел да укучылар 12 оя ясап килгәннәр иде. Аларның кайберләрен ярминкәдә саттылар да әле.

Уен уен белән, ә менә Нәүрүзнең иң “тәмле” өлеше – сату инде. Башка төрле товарлар яхшы сатылмаганлыктан, укучылар гадәттә өйләрендә әзерләнгән ризыклар белән сату итә. Сатып алучылар да шуны гына көтеп торганлыктан, ярминкә өстәлләре күз ачып йомган арада бушап кала. Ахырдан балалар шатланышып товар сатып эшләгән акчаларын саный.

Быелгы Нәүрүз бәйрәме бераз моңсулык булды – бизәлгән атлар җигеп авыл буйлап урам әйләнү уздырылмады. Моның төп сәбәбе – авылда җигәргә өйрәтелгән атларның калмавы. Шулай да, кәефне төшермичә, киләчәктә атта йөрү мөмкинлеге булыр әле дигән теләктә калыйк.

***Айназ Хәйруллин, VII сыйныф укучысы***

## /Котлыйбыз!/




Март аенда туган дусларыбыз **Хусенов Диманы** (II сыйныф), **Вәлиев Ибраһимны** (V сыйныф), **Морадимов Илсурны** (IX сыйныф), **Сафиуллина Зөлфирәне** (X сыйныф) туган көннәре белән котлыйбыз. Аларга укуларында зур уңышлар, сәламәтлек, барча хыялларының тормышка ашуларын телибез. Сезгә тырышлык белән намус һәрвакыт юлдаш булсын, дуслар!

Яраткан укытучыбыз, гәзитебезнең мөхәррире **Фәнүзә апаны** да туган көне белән тәбрик итәбез! Хөрмәтле Фәнүзә апа! Сезгә алдагы тормышыгызда гаилә бәхете, ныклы сәламәтлек, мактаулы эшегездә зур уңышларга ирешүегезне телибез!

***“Мәктәп хәбәрчесе” редколлегиясе***